| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ФЕДОТОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ФЕДОТОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19 октября 2023 ГОДА** с. Федотовка № 37

«Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Советы КАРАР БИРДЕ:

1. « Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8.2.3, 8.3.1 пунктларда «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.»;

9.5 пунктта «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

9 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 9.5.1 пункт өстәргә:

«9.5.1. Муниципаль хезмәткәрләргә 9.5 пунктында күрсәтелгән бүлә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

19 нчы бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 19.4.15 пункты белән тулыландырырга:

«19.4.15.Муниципаль хезмәткәр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, коррупциягә каршы тору максатларында башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен һәм бурычларны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләр, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган шартлар нәтиҗәсе булып танылa икән, җаваплылыктан азат ителә.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы,

Федотовка авылы, Совет ур., 6, Совет ур., 8 (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив ур., 10 (СК бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Федотовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе В.И.Павлова